**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

---

**2026 елның 6 мае** **42-РС номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының аерым карарларын үз көчен югалткан дип тану турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ нче номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставына, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне кабат бүлешү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында»гы карарга, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы «Комлы Ковал авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планын раслау турында» 2026 елның 27 февралендәге 348/о номерлы Боерыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы «Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планын раслау турында» 2026 елның 27 февралендәге 346/о номерлы Боерыгы белән, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы «Орёл авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планын раслау турында» 2026 елның 27 февралендәге 344/о номерлы Боерыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы «Никольское авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планын раслау турында» 2026 елның 27 февралендәге 343/о номерлы Боерыгы нигезендә, Лаеш муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2022 елның 27 июнендәге «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Никольское авыл җирлегенең Генераль планын раслау турында»гы 48-РС номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2018 елның 16 февралендәге «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Орёл авыл җирлегенең генераль планын раслау турында»гы 11-РС номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2025 елның 7 февралендәге «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Комлы Ковал авыл җирлегенең Генераль планын раслау турында»гы 6-РС номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны «Камская новь» район газетасында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча) һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталындагы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында (http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
5. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылган (халыкка җиткерелгән) көненнән башлап үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктураны үстерү буенча урынбасары И.П. Шитовка йөкләргә.

**Муниципаль район башлыгы –**

**Совет рәисе:** **И.Ф. Зарипов**